

Әйе, Ичалки Конезаводына еш кына балалар классляры белән бергә дә, аерым-аерым да экскурсиягә баралар; анда бик тә кызыклы һәм саулыкка да бик тә файдалы. Темников районында шундый матур эшләр башкаручыны беләбез. Ул - Митрял имамы Рафаиль Ханәфи улы Ялышев (рәсемдә улы Ильнур белән). Темник районында физик кимчелекле балалар очен интернат-йортта («Темниковский детский дом-интернат для детей с физическими недостатками») яшәvче балаларны оенә алып кайтып кунак итә һәм vзе асраган атка атланып иппотерапия дә vткәрә. Ә августта Удмуртиядә иппотерапия фестивале узган. Ижау ипподромы әлеге фестивальне «ВАЛТАУ» хәйрия фонды белән бергә оештырган. Фестивальдә атлар ярдәмендә сәламәтләндерv һәм тернәкләндерv белән шогыльләнvче оешмалар катнашкан. Оештыручылар кvнел ачу программасы әзерләгәннәр: атлар ярдәмендә чыгышлар кvрсәткәннәр, атларда бушлай йорv, фотосессияләр булган, шулай ук рәсем конкурсына йомгак ясалган.

Чыгыш ясаучы балалар тамашачыларны кvреп, шатлык хисләре кичергәннәр. Белгечләр иппотерапиянен файдасы һәм момкинлекләре турында белешмә биргәннәр. Момкинлекләре чикләнгән балаларнын әти-әниләренә иппотерапевтлар, диетологлар, бала хокуклары буенча белгечләр белән аралашу, кызыксындырган барлык сорауларга җавап табу момкинлеге булган.

Иппотерапия - атлар яки пони ярдәмендә дәвалау алымы. Гәvдән тоз булсын дисән, атта йорергә кирәк. Наркотикларга һәм алкогольгә бәйле затлар бу хайваннар белән кvбрәк аралашса, тернәкләнv момкинлеге зуррак икән. Белгечләр полиомиелит, сколиоз, балаларнын церебраль параличы булганда атта йорvнен нәтиҗәле булуын кvптән исбатлаган. Ат ярдәмендә дәвалау vзәкләре бик кvп илләрдә эшли. Ижау ипподромында да иппотерапияне кулланалар. Голнара Вәлиева, «Янарыш» газетасында болай ди: «Тренер Валерия Рябова әйтvенчә, атлар янында балалар тынычлана, доньяны танып белvләре җинеләя, атта йоргәннән сон мускуллары йомшара. Ул 10 елдан артык балалар белән шогыльләнә. Безнен максат – баланы тынычландыру. Балалар, беренче чиратта, атта йорергә дип килә. Шунлыктан алар атлардан курыкмыйлар. Ә без аларны ат остенә утырган килеш торле кvнегvләр, хәрәкәтләр ясарга ойрәтәбез. Массаж ясаган вакытта, балалар елый, аларнын тәне авырта. Атта йоргәндә, баланын арка мускуллары табигый рәвештә ныгый, ләкин ул массаждагы кебек унайсызлык кичерми. Шулай ук куллары белән божраны ике кулы белән тотып барганда, аттан егылмас очен, аяклары белән

атны кысып утыралар. Аяк мускуллары да ныгый», – ди ул.

**Наилә Насырова**